Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылы
**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

«19» ноябрь, 2021 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Калиновка авылы гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «2022 елда яшәү урыны буенча Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны ремонтлау (вак таш, ком, асфальт валчыгы сатып алу, китерү, җәю);
- электроматериаллар сатып алу, урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру;
- зиратны төзекләндерү (хуҗалык инвентаре өчен бина урнаштыру).

2. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Калиновка авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Ю.М. Рыбакова